ГОСУДАРСТВЕННЫЙ
КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ
РЕСУРСАМ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР
БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ
КОМИТЕТЫ

---

**Приказ** **Боерык**

02.11.2017 Казан шәһәре № 160-од

Татарстан Республикасының
Биологик ресурслар буенча дәүләт
комитетында Татарстан
Республикасының дәүләт
гражданлык хезмәтенең буш урынын
алмаштыру өчен (кадрлар резервына
кертү) бәйге үткәрү турындагы
Кагыйдәнамәне раслау турында

2004 елның 27 июленән № 79-ФЗ “Россия Федерациясенә дәүләт гражданлык хезмәте күрсәтү турында”гы Федераль канун белән, 2005 елның 1 февраленнән № 112 “Россия Федерациясенә дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен бәйге турында”гы Россия Федерациясе Президенты Боерыгы белән,2003 елның 16 гыйнварыннан № 3-ЗРТ “Татарстан Республикасына дәүләт гражданлык хезмәте күрсәтү турында”гы Татарстан Республикасы Кануны белән тәңгәл килеп **б о е р а м :**

1. Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен (кадрлар резервына кертү) бәйге үткәрү турындагы Кагыйдәнамәне расларга.
2. Бу боерыкның үтәлүен тикшерүне үз артымнан калдырам.

Рәис Ф.С. Батков

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 02.11.2017 елдан 160-од номерлы боерыгы белән расланган

**Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен (кадрлар резервына кертү) бәйге үткәрү турында кагыйдәнамә.**

## I. Гомуми кагыйдәләр

1.1. Гамәлдәге Кагыйдәнамә белән Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен (кадрлар резервына кертү) бәйге үткәрү комиссиясенең катнашмасы, эш вакыты һәм тәртибе (алга таба - бәйге комиссиясе), ә шулай ук Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында (алга таба – Комитет) Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен (кадрлар резервына кертү) бәйгене үткәрү методикасы билгеләнә.

1.2. Комитетта Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен бәйге( алга таба – бәйге) уздыруның төп бурычлары:

Россия Федерациясе гражданнарының, Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенә бертигез дәрәҗәдә хокук бирү конституция белән тәэмин итү (алга таба – гражданлык хезмәте);

Комитетта Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләрен (алга таба – гражданлык хезмәткәрләре) бәйге нигезендә хезмәттәге үсеш хокукы белән тәэмин итү;

бәйге нигезендә югары һөнәрле кадрлар катнашмасын сайлап алу һәм формалаштыру;

кадрларны табу һәм билгеләү буенча эшне камилләштерү.

1.3. Бәйгеләрне уздырганда чишелә торган мәсьәләләр:

бәйге биремнәрен һәм процедураларын эшләгәндә, барлык кандидатлар өчен дә тигез шартлар тәэмин итү;

гражданлык хезмәте культурасына ,һөнәри компетентлыкка һәм шәхси - эшлеклелеккә тәңгәл килү критерийлары нигезендә кандидатларны бәяләү;

бәйге катнашучылары арасында, бәйге биремнәрен һәм процедураларын эшләү нәтиҗәләрен чагыштыру юлы белән, Комитетта Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынына (кадрлардагы буш урынның гражданлык хезмәте вазифалары) куела торган таләпләргә туры килүче затларны билгеләү;

1.4. Комитетта бәйге 2004 елның 27 июленән № 79-ФЗ “Россия Федерациясенә дәүләт гражданлык хезмәте күрсәтү турында”гы Федераль канунның ( алга таба - Федераль канун) 22 маддәсе, 2005 елның 1 февраленнән № 112 “Россия

Федерациясенә дәүләт гражданлык хезмәтенә буш урынны алмаштыру өчен бәйге турында”гы Россия Федерациясе Президенты боерыгы, 2003 елның 16 гыйнварыннан № 3-ЗРТ “Татарстан Республикасына дәүләт гражданлык хезмәте күрсәтү турында”гы Татарстан Республикасы кануны, 2011 елның 14 мартыннан УП-127 номерлы “Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтендә кадрлардагы буш урын турында Кагыйдәнамәне раслау турында”гы Татарстан Республикасы Президенты боерыгы, 2015 елның 11 декабреннән УП-1192 номерлы “Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын алмаштырырга теләүче гражданнарга тест узуны оештыру сораулары” Татарстан Республикасы Президенты боерыгы нигезендә уздырыла.

1.5. Комитетта бәйге, аны алмаштыру Федераль канунның 22 маддәсе белән тәңгәл килеп, бәйге нигезендә уздырылырга мөмкин булган, гражданлык хезмәтендә буш урын (гражданлык хезмәткәре белән алмаштырылмаган) булган очракта, Комитет рәисе карары буенча игълан ителә.

Бәйгене уздыру турында карар, Комитет рәисе белән, Комитетның кадрлар хезмәте әзерләгән, мотивлаштырылган язма гариза нигезендә кабул ителә.

Гариза, бәйге уздыру турында тәкъдим белән беррәттән, гражданлык хезмәте вазифасының исемен һәм хезмәттәге бурычларының үзенчәлекләрен күздә тотарга, эзләүчегә куела торган таләпләрне үз эченә алырга тиеш. (Кагыйдәнамәнең 3нче кушымтасы)

1.6. Комитетта бәйге үткәрелми:

Комитетта гражданлык хезмәтенең “башлыклар” һәм “булышчылар (киңәшчеләр)” категориясенә билгеле бер вакытка эшкә билгеләнгән очракта;

срогы булган хезмәт контракты төзелгән очракта;

гражданлык хезмәткәрен, 2004 елның 27 июленән № 79-ФЗ “Россия Федерациясенә дәүләт гражданлык хезмәте күрсәтү турында”гы Федераль канунның 28 маддәсенең 2 бүлегендә, 31 маддәнең 1 бүлегендә һәм 60.1. маддәнең 9 бүлегендә каралган, башка гражданлык хезмәтенә билгеләгән очракларда;

гражданнар хезмәте резервына кертелгән гражданинны гражданлык хезмәтенә билгеләнгән очракларда;

1.7. Бәйге үткәрелмәскә мөмкин:

Комитет боерыгы белән раслана торган вазифалар исемлеге буенча, хезмәтне үтәү, дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматлар белән бәйле булган, гражданлык хезмәтенең аерым вазифаларына билгеләгән очракта;

Комитет рәисе карары буенча, гражданлык хезмәтенең кече вазифаларына билгеләгән очракта;

1.8. Бәйге, гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыручы кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен билгеләүдән, аларның бу вазифага куелган һөнәрчелек таләпләренә туры килүен бәяләүдә тора.

## II. Бәйге комиссиясенең формалашу һәм эш тәртибе.

2.1. Бәйге үткәрү өчен, Комитет боерыгы белән, дңаими рәвештә эшли торган бәйге комиссиясе оештырыла. Бәйге комиссиясенең катнашмасы Комитет боерыгы белән раслана.

Гражданлык хезмәтенең башка буш урыннарын алмаштыруга бәйгеләр уздыру өчен, Комитет рәисе боерыгы белән, гражданлык хезмәтенең төрле дәрәҗәсе һәм төркеме өчен, берничә бәйге комиссиясе оештырылырга мөмкин.

2.2. Комиссия рәисе бәйге комиссиясе эшчәнлеге белән идарә итә, утырышны үткәрү вакытын һәм аның көн тәртибен билгели, комиссия утырышларында рәислек итә һәм документларга имза куя. Комиссия рәисе булмаган очракта, аның хокукларын һәм бурычларын бәйге комиссиясе рәисенең урынбасары үти.

Бәйге комиссиясенең сәркатибе комиссиянең эшен тәэмин итә (регистрацияләү, гаризаларны кабул итү, комиссиянең беркетмәләрен алып бару).

2.3. Бәйге комиссиясенең катнашмасына Комитет рәисе, Комитет рәисенең урынбасары, дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторы мөдире, хокукый сораулар буенча алдынгы киңәшче һәм гражданлык хезмәте вазифасын алмаштыруга бәйге уздырыла торган Комитетның структур бүлекчәләре җитәкчеләре, Татарстан Республикасы Президенты карамагындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар Департаменты вәкиле, Комитет карамагындагы Иҗтимагый киңәшмә вәкилләре, ә шулай ук Комитет рәисе соравы буенча, Татарстан Республикасы Президенты карамагындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар Департаменты белән чакырылган, гражданлык хезмәте буенча бәйсез экспертлар булып, шәхси мәгълүматларны күрсәтмичә, фәнни, уку-укыту оешмаларының һәм башка оешмаларның вәкилләре кертелә.

Комитет карамагындагы Иҗтимагый кинәшмә вәкилләре һәм бәйсез экспертларның гомуми саны, бәйге комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан, дүртнең бер өлешеннән дә ким булмаска тиеш.

2.4.Комитетта гражданлык хезмәтен үтәү, дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматлар белән бәйле булса, Татарстан Республикасына дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен (кадрлар резервына кертү) бәйге үткәрү комиссиясе катнашмасы Россия Федерациясенең дәүләт сере турындагы кануннарын исәпкә алып формалаша.

2.5. Бәйге комиссиясенең катнашмасы, бәйге комиссиясенең кабул итә торган карарларына йогынты ясый торган, ихтыяҗлар бәрелеше булмауны искәртеп формалаштырыла.

2.6. Бәйге комиссиясенең утырышы Комитетта гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыруга (кадрлар резервына кертүгә) ике кандидаттан да ким булмаган очракта уздырыла һәм аның гомуми әгъзаларыннан өчтән ике өлеше булган очракта хокуклы дип санала. Гражданлык хезмәтендәге урыннарны алмаштыручы, комиссия әгъзалары гына катнашкан, утырышны уздыру ярамый.

2.7.Бәйге уздыру нәтиҗәләре буенча, бәйге комиссиясенең карары, утырышта булган бөтен әгъзаларның ачык тавыш бирүе белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч була. Бәйге комиссиясенең теләсә кайсы әгъзасы, кабул иткән карар белән килешмәсә, үзенең аерым карашын

белдерә ала. Аны комиссия утырышының беркетмәсенә теркиләр һәм шул бәйге комиссиясе әгъзаның имзасы белән беркетәләр.

2.8. Бәйге комиссиясенең карары кандидат үзе булмаган вакытта кабул ителә һәм аны гражданлык хезмәтенең буш урынына билгеләүнең, кадрлар резервына кертүнең яки кире кагуның нигезе булып тора.

Бәйге комиссиясе шулай ук, гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен бәйгедә җиңмәгән, ләкин аның һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәя алган, кандидатны, Комитетның кадрлардагы буш урынга кертү турында, тәкъдим итү характерындагы карар кабул итәргә мөмкин.

2.9. Бәйге комиссиясенең әгъзалары белән кабул ителгән карарлар (комиссиянең тавыш бирү нәтиҗәләре), бәйге комиссиясенең беркетмәсе (гамәлдәге Кагыйдәнамәгә 5нче кушымта) белән рәсмиләштереләләр. Аңа рәис, рәиснең урынбасары, сәркатип, комиссия әгъзалары һәм утырышта катнашкан бәйсез эксперт белән кул куела.

2.10. Бәйгене уйлау һәм әзерләү буенча эш документларының эчтәлеге, бәйге комиссиясенең утырыш беркетмәләре, бәйге утырышларының сораулары һәм темалары исемлеге бәйге беткәнчегә кадәр, хезмәт кулланнуы өчен мәгълүмат булып тора.

2.11.Бәйгене, бәйге комиссиясенең эшен оештыру һәм уздыру бәйге комиссиясенең сәркатибе башкара.

## III. Бәйгедә катнашучылар

3.1. Бәйгедә катнашуга, Идарәдә гражданлык хезмәтендәге буш урынны алмаштыруга (кадрлар резервына кертү) куелган таләпләргә туры килгән һәм бирелгән вакыт эчендә бөтен кирәкле документларны тапшырган, гражданнар кертелә.

3.2.Идарәдә гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыручы кандидатларга (кадрлар резервына кертү) куелган таләпләр (гамәлдәге Кагыйдәнамәгә 1нче кушымта) һәм Комитетта гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыручы (кадрлар резервына кертү) кандидатларга бирелә торган әсбаплар һәм документлар исемлеге (гамәлдәге Кагыйдәнамәгә 2нче кушымта) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте турындагы кануннар нигезендә урнаштырылды.

## IV. Бәйгене үткәрү методикасы

4.1. Бәйгене үткәргәндә, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының кануннарына каршы килмәгән, кандидатларның шәхси һәм һөнәри сыйфатларын бәяләү методларына нигезләнгән бәйге биремнәре һәм эшләре кулланыла.

4.2. Кандидатларның шәхси һәм һөнәри сыйфатларын бәяләүнең критерийлары, Комитетның гражданлык хезмәте вазифаларына куела торган һөнәрчелек таләпләре нигезендә эшкәртелде.

Бәйге үткәрелә торган төркемгә һәм вазифаның категориясенә карап, бәйгедә катнашучыларны бәяләү критерийлары үзгәрергә мөмкин.

4.3. Бәйге уздырганда, бәйге комиссиясе, кандидатларның белем алуын, гражданлык яки башка дәүләт хезмәтен үтүен, башка урында эшләвен, тапшырган документлар, тест һәм башка бәйге процедуралары, ә шулай ук Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы кануннарына каршы килмәгән, кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларын кулланып, шул санда Комитетта гражданлык хезмәтендәге буш урынны (гражданлык хезмәтенең кадрлар резервы вазифалары) алмаштырырга теләүче кандидатлар, шул вазифа буенча вазифаи бурычларын үтәү белән бәйле сораулар буенча, тест һәм шәхси әңгәмә уздыру нигезендә бәяли.

4.4. Комитетта гражданлык хезмәтендәге буш урынны (гражданлык хезмәтенең кадрлар резервы вазифалары) алмаштырырга теләүче кандидатларга тестны уздыру, Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә, дәүләт гражданлык хезмәтендәге буш урынны алмаштырырга теләүче гражданнарга, Татарстан Республикасы Президенты карамагындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар Департаментының 11.01.2016 елдан 1нче номерлы карары белән расланган, тест уздыру Методикасы белән тәңгәл килеп алып барыла.

4.5. Бәйге ике этапта уздырыла.

Беренче этапта Комитет документларны кабул итү турында белдерүне Комитетның рәсми сайтында һәм дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт системасында “Интернет” мәгълүмати- телекоммуникация челтәрендә урнаштыра.Шулай ук бәйге турында киләсе мәгълүмат күрсәтелә: гражданлык хезмәтендәге буш вазифаның исеме, бу вазифаны алмаштыру өчен кирәкле һөнәрчелек таләпләре, гражданлык хезмәтен үтү шартлары, бу Кагыйдәнамәнең 2 нче кушымтасына карап бирергә кирәкле документларны кабул итү вакыты һәм урыны, күрсәтелгән документларның кайсы вакытка кадәр кабул ителүе, бәйге үткәрүнең якынча вакыты, аны үткәрүнең урыны һәм тәртибе,бүтән мәгълүмати әсбаплар.

Бәйгедә катнашу өчен документларны кабул итү турында белдерү һәм бәйге турында мәгълүмат, шулай ук вакытлы матбугатта да бастырыла ала.

4.6. Бу Кагыйдәнамәнең 2 нче кушымтасында курсәтелгән документлар, аларны кабул итү турында белдерүне Комитетның рәсми сайтында һәм дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт системасында “Интернет” мәгълүмати- телекоммуникация челтәрендә урнаштырган көннән алып 21 көн эчендә, гражданин (гражданлык хезмәткәре) белән шәхси, почта аша яки электрон рәвештә Комитетка тапшырылалар.

Бәйгенең беренче этабы документларны кабул итү турында белдерүне Идарәнең рәсми сайтларында һәм “Интернет” челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт информацион системасында урнаштыру көненнән алып башлана һәм 21 көннән дә иртә тәмамланмый.

Документларны электрон рәвештә тапшыру тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте белән билгеләнә.

4.7. Документларны сәбәпсез үз вакытында тапшырмау, тулы күләмдә тапшырмау яки тутыру кагыйдәләрен бозу, гражданинга (гражданлык хезмәткәренә) аларны кабул итүдә кире кагу өчен нигез булып тора.

Документларны сәбәбе булып үз вакытында тапшырмау, тулы күләмдә тапшырмау яки тутыру кагыйдәләрен бозу очрагында, Комитет рәисе аларны кабул итү вакытын күчерергә мөмкин.

4.8. Гражданинның (гражданлык хезмәткәренең) ризалыгы белән, аңа дәүләт яки башка канун белән саклана торган серне тәшкил иткән мәгълүматларны карарга рөхсәт бирү процедурасы башкарыла, әгәр дә, гражданин алмаштырырга теләүче гражданлык хезмәте буенча, гражданлык вазифаларын үтәү, андый мәгълүматларны куллану белән бәйле булган очракта.

Гражданин белән дәүләт әгъзасына тапшырылган мәгълүматларның дөреслеге тикшерелергә тиеш. Электрон рәвештә тапшырылган мәгълүматлар, Россия Федерациясе Хөкүмәте белән билгеләнгән тәртиптә, автомат рәвештә тикшереләләр.

Гражданлык хезмәткәре белән тапшырылган мәгълүматларның дөреслеге, гражданлык хезмәтенең югары төркем вазифаларга караган гражданлык хезмәтендәге буш урынны алмаштыру өчен бәйгедә катнашкан очракта гына тикшерелә.

4.9. Бәйгенең беренче этабы бетүенең шарты, кандидатларны алга таба сайлау мөмкинлеген тәэмин итеп, куелган таләпләргә туры килүче ике яки икедән артык кандидат булу.

4.10. Бәйгенең икенче этабын уздыру вакыты һәм урыны турында карар, Комитет рәисе белән, гражданлык хезмәтендәге буш урынны алмаштырырга теләүче претендентлар тапшырган мәгълүматларны тикшергәннән соң, ә шулай ук кирәк булса, дәүләт яки башка канун белән саклана торган серне тәшкил иткән мәгълүматларны карарга рөхсәт бирелгәннән соң кабул ителә. Бәйгенең икенче этабы, бәйгедә катнашу өчен документларны кабул итү көненнән соң, 30 календарь көннән дә соңга калмыйча уздырыла, әгәр дә дәүләт яки башка канун белән саклана торган серне тәшкил иткән мәгълүматларны карарга рөхсәт бирү кирәк булса, бәйгенең икенче этабын уздыру вакыты Комитет рәисе белән билгеләнә.

Тикшерү барышында, Федераль кануннар һәм Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актлары белән тәңгәл килеп, гражданинның гражданлык хезмәтенә керүгә киртә була торган шартлар ачыкланган очракта, ул бәйгедә катнашуга кертелмәү сәбәпләре турында (гамәлдәге Кагыйдәнамәнең 4 нче кушымтасы) карар кабул ителгән көннән алып 3 көн эчендә, язма рәвештә яллаучының вәкиле белән белдерелә. Әгәр дә гражданин бәйгедә катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган очракта, аңа, бәйгедә катнашуга кертелмәү сәбәпләре турында, дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмати системасы аша электрон документ рәвешендә, көчәйтелгән махсус электрон имза куелып хәбәр җибәрелә.

4.11. Бәйгедә катнашуга кертелмәгән, буш урынны алмаштырырга теләүче претендент, Россия Федерациясе кануннары белән тәңгәл килеп, ул карарны шикаять итәргә хокуклы.

4.12. Комитет бәйгенең икенче этабы башланганчы 15 көн алдан Комитетның рәсми сайтында һәм дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт системасында "Интернет" мәгълүмати- телекоммуникация челтәрендә бәйгене уздыру вакыты, урыны, бәйгегә кертелгән гражданнар (гражданлык хезмәткәрләре) исемлеген урнаштыра һәм кандидатларга язма рәвештә туры килә торган хәбәрләр җибәрә. Әгәр дә гражданин бәйгедә катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган очракта, дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмати системасы аша электрон документ рәвешендә, көчәйтелгән махсус электрон имза куелып хәбәр җибәрелә.

4.13. Бәйге нәтиҗәләре буенча Комитет рәисе белән, бәйгенең җиңүчесен гражданлык хезмәтенең буш урындагы вазифага билгеләү турында боерык бастырыла һәм җиңүче белән хезмәт контракты төзелә.

Әгәр дә бәйге комиссиясе белән, гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен уздырылган бәйгедә, Комитетның кадрлар резервына, җиңмәгән кандидатны кертергә карар чыгарылган булса, ул очракта күрсәтелгән затның ризалыгы буенча, аны гражданлык хезмәтендәге буш урындагы вазифа караган төркемдәге, гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен Комитетның кадрлар резервына кертү турында боерык бастырыла

4.14. Бәйге нәтиҗәләре турында хәбәр, бәйге тәмамланганнан соң 7 көн эчендә кандидатларга язма рәвештә җибәрелә. Әгәр дә гражданин бәйгедә катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган очракта, дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмати системасы аша электрон документ рәвешендә, көчәйтелгән махсус электрон имза куелып хәбәр җибәрелә. Бәйге нәтиҗәләре турында мәгълүмат шул ук вакытта Комитетның рәсми сайтларында һәм "Интернет" челтәрендә күрсәтелгән мәгълүмати системада урнаштырыла.

4.15.Гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштырырга теләгән, ләкин бәйгегә кертелмәгән, яки катнашып җиңмәгән кандидатларның документлары язма рәвештәге гариза буенча, бәйге беткәннән соң, өч ел эчендә кайтарылырга мөмкин. Ул вакыт үткәнчегә хәтле документлар Комитетның архивында саклананалар, аннан соң юк ителәләр. Бәйгедә катнашу өчен электрон рәвештә бирелгән документлар, өч ел саклананалар, аннары юк ителәләр.

4.16.Бәйгедә катнашу белән бәйле чыгымнар (бәйге үткәрү җиренә бару һәм кайту өчен түләү, бүлмәдә түләп вакытлыча тору, элемтә өчен түләү һ.б.), кандидатлар белән үз акчасыннан түләнә.

4.17. Кандидат,бәйге комиссиясенең карарын, Россия Федерациясе кануннары белән тәңгәл килеп, шикаятьләргә мөмкин

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен (кадрлар резервына кертү) бәйге үткәрү кагыйдәнамәсенә 1нче кушымта.

**Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыручы (кадрлар резервына кертү) кандидатларга куелган таләпләр.**

I. Гомуми таләпләр

1.1. 18 яшьтән дә кече булмаган, Россия Федерациясенең дәүләт телендә сөйләшүче, Комитетта Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен (кадрлар резервына кертү) кирәкле Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының кануннары белән билгеләнгән таләпләргә туры килгән, Россия Федерациясенең гражданнары бәйгедә катнашырга хокуклы.

Гражданлык хезмәткәре, бәйге уздыру вакытында нинди вазифаны алмаштыруга карамыйча, гомуми нигезләрдә бәйгедә катнашырга хокуклы.

1.2. Гражданин (гражданлык хезмәткәрләре), гражданлык хезмәте вазифасын алмаштыру өчен, һөнәрчелек таләпләренә туры килмәү белән бәйле рәвештә, ә шулай ук гражданлык хезмәтенә керү һәм аны узу өчен, дәүләт гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы кануннары белән билгеләнгән чикләүләр белән бәйле рәвештә бәйгедә катнашуга кертелми.

1.3. Комитетның кадрлар резервына, Федераль канунның 57 маддә 1 бүлек 2 яки 3 пунктлары яисә 59.1 маддә 2 яки 3 пункты белән каралган, тәртип ягыннан шелтәсе булган дәүләт хезмәткәре кертелә алмый.

II. Һөнәрчелек таләпләре

2.1. Гражданлык хезмәте вазифаларын алмаштыру өчен,вазифаи бурычларны үтәү өчен кирәкле һөнәри белем дәрәҗәсенә, гражданлык хезмәте яки белгечлек буенча эш стажына, әзерлек, белдм һәм осталык юнәлешенә һөнәрчелек таләпләренең туры килүе, ә шулай ук Комитет рәисенең белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә туры килүче карар булуы таләп ителә.

2.2. Гражданлык хезмәте вазифаларын алмаштыру өчен, һөнәрчелек таләпләре гражданлык хезмәте вазифаларының дәрәҗәләре һәм төркемнәре, гражданлык хезмәткәренең профессиональ хезмәт эшчәнлеге өлкәсе һәм төре белән туры килеп билгеләнәләр.

2.3. Профессиональ белем дәрәҗәсенә һөнәри таләпләр:

гражданлык хезмәтенең югары һәм төп вазифа төркемнәренең “җитәкчеләр”, “булышчылар”(“киңәшчеләр”), “белгечләр” дәрәҗәсендәге гражданлык хезмәте вазифаларын алмаштыру өчен, магистратура белгеченнән дә ким булмаган югары белемле булу мәҗбүри;

гражданлык хезмәтенең әйдәп баручы вазифа төркемнәренең “җитәкчеләр”, “булышчылар”(“киңәшчеләр”) дәрәҗәсендәге гражданлык хезмәте вазифаларын һәм гражданлык хезмәтенең әйдәп баручы һәм югары вазифа төркемнәренең “белгечләр” дәрәҗәсендәге гражданлык хезмәте вазифаларын, ә шулай ук гражданлык хезмәтенең төп һәм әйдәп баручы вазифа төркемнәренең “тәэмин итүче белгечләр” дәрәҗәсендәге гражданлык хезмәте вазифаларын алмаштыру өчен, югары белемле булу мәҗбүри.

2.4. Гражданлык хезмәткәрләренә, гражданлык хезмәте вазифаларын алмаштыру өчен кирәкле, гражданлык хезмәте яки белгечлек буенча эш стажына, әзерлек юнәлешенә куела торган һөнәрчелек таләпләре:

гражданлык хезмәтенең югары вазифа төркемнәренең “җитәкчеләр”, “булышчылар”(“киңәшчеләр”), дәрәҗәсендәге гражданлык хезмәте вазифаларын алмаштыру өчен - өч елдан да ким булмаган гражданлык хезмәте стажы яки җиде елдан да ким булмаган белгечлек буенча эш стажы, әзерлек юнәлеше;

гражданлык хезмәтенең югары вазифа төркемнәренең “белгечләр”, дәрәҗәсендәге гражданлык хезмәте вазифаларын алмаштыру өчен – өч елдан да ким булмаган гражданлык хезмәте стажы яки биш елдан да ким булмаган белгечлек буенча эш стажы, әзерлек юнәлеше;

гражданлык хезмәтенең төп вазифа төркемнәренең бөтен дәрәҗә гражданлык хезмәте вазифаларын алмаштыру өчен - ике елдан да ким булмаган гражданлык хезмәте стажы яки өч елдан да ким булмаган белгечлек буенча эш стажы, әзерлек юнәлеше;

гражданлык хезмәтенең әйдәп баручы вазифа төркемнәренең бөтен дәрәҗә гражданлык хезмәте вазифаларын алмаштыру өчен - бер елдан да ким булмаган гражданлык хезмәте стажы яки ике елдан да ким булмаган белгечлек буенча эш стажы, әзерлек юнәлеше.

Гражданлык хезмәте стажын билгеләгәндә, шулай ук аңа федераль дәүләт хезмәтендә, хәрби хезмәттә туры килгән вазифа төркемнәре, федераль дәүләт хезмәтендә башка төр вазифалар, муниципаль хезмәт вазифаларындагы, туры килүче төркемнәрнең муниципаль хезмәт вазифаларындагы, федераль кануннар белән тәңгәл килеп башка вазифаларда эшләгән стаж санала.

2.5. Бу Кагыйдәнамәнең 2.4. пункты белән урнаштырылган, гражданлык хезмәте яки белгечлек буенча эш стажына, әзерлек юнәлешенә һөнәрчелек таләпләре, эшчәнлек юнәлешенә туры килә торган, гыйльми дәрәҗәгә ия булган затлар белән, гражданлык хезмәтенең төп һәм әйдәп баручы вазифа төркемнәренең

“булышчылар”(“киңәшчеләр”) дәрәҗәсендәге гражданлык хезмәте вазифаларын һәм гражданлык хезмәтенең төп һәм әйдәп баручы вазифа төркемнәренең “белгечләр” дәрәҗәсендәге гражданлык хезмәте вазифаларын алмаштырганда, Комитет рәисе карары буенча саналмаска мөмкин.

2.6. Белгеч яки магистр кызыл дипломына ия булган затларга, дипломны биргән көннән соң өч ел эчендә, гражданлык хезмәтенең әйдәп баручы вазифаларын алмаштыру өчен, гражданлык хезмәте яки белгечлек буенча эш стажына, әзерлек юнәлешенә, гражданлык хезмәте яки белгечлек буенча эш стажы, әзерлек юнәлеше бер елдан да ким булмаган һөнәрчелек таләпләре урнаштырыла.

2.7. Вазифаи бурычларны үтәү өчен кирәкле, белемнәргә һәм осталыкка куела торган һөнәрчелек таләпләре, гражданлык хезмәткәренең профессиональ хезмәт эшчәнлеге өлкәсеннән һәм төреннән, аның вазифаи регламентыннан чыгып билгеләнәләр. Гражданлык хезмәткәренең вазифаи регламенты белән, гражданлык хезмәте вазифаларын алмаштыру өчен кирәкле, һөнәрчелеккә, әзерлек юнәлешенә куелган таләпләр күздә тотылырга мөмкин.

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен (кадрлар резервына кертү) бәйге үткәрү кагыйдәнамәсенә 2 нче кушымта.

**Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыручы (кадрлар резервына кертү) кандидатлар бирә торган документлар һәм әсбаплар ИСЕМЛЕГЕ.**

1.1. Бәйгедә катнашырга теләүче Россия Федерациясе гражданы, Комитетка киләсе документларны тапшыра:

1) шәхси гариза (бу Исемлеккә кушымта);

2) Россия Федерациясе Хөкүмәте белән расланган формада, үз кулы белән тутырган һәм имза куйган, фотографиясен беркеткән анкета;

3) паспорт яки аны алмаштыручы документның күчермәсен (документ шәхси бәйгегә килгәч күрсәтелә);

4) кирәкле һөнәри белем алуны, һөнәрчелекне һәм эш стажын раслый торган документлар:

эш урыны буенча кадрлар хезмәте яки нотариус белән расланган,эш китабының күчермәсе ( искәрмә артыннан эшчәнлек беренче тапкыр алып барылган очракларда),яки гражданның хезмәт эшчәнлеген раслый торган башка документлар;

эш урыны буенча кадрлар хезмәте яки нотариус белән расланган, һөнәри белем алу, һөнәрчелек турында документларның күчермәсе, ә шулай ук теләк буенча өстәмә белем алу нәтиҗәләре буенча һөнәрчелек алуны яки күтәрүне раслый торган документларның күчермәсен, фәнни дәрәҗә, фәнни исем алу турында документларның күчермәсен;

5) гражданинда, гражданлык хезмәтенә керергә яки аны үтәргә кымачаулый торган, авыру булмау турында документ;

6) 2004 елның 27 июленән № 79-ФЗ “Россия Федерациясенә дәүләт гражданлык хезмәте күрсәтү турында”гы Федераль канун, башка федераль кануннар, Россия Федерациясе Президенты боерыклары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары белән каралган, башка документлар.

1.2. Комитетта гражданлык хезмәте вазифасын алмаштыра торган гражданлык хезмәткәре, анда уздырыла торган бәйгедә катнашырга теләгән очракта, Комитет рәисе исеменә гариза яза. Башка дәүләт әгъзасында уздырыла торган бәйгедә катнашырга теләгән гражданлык хезмәткәре, Комитетка Комитет рәисе исеменә гариза һәм үз кулы белән тутырган, имза куйган һәм гражданлык хезмәткәре, гражданлык хезмәте вазифасын алмаштыра торган дәүләт әгъзасының кадрлар

хезмәте белән расланган, Россия Федерациясе Хөкүмәте  боерыгы белән расланган форма буенча, фотографиясен теркәгән анкета тапшыра.

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында
Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыручы (кадрлар резервына кертү) кандидатлар бирә торган документлар һәм әсбаплар исемлегенә кушымта

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисенә

________________________________________
(инициаллар, фамилия)

______________________________________
(фамилия, исем, атасының исеме)

________________________________________

Торам____________________________

________________________________________

Тел. ___________________________________
(эш телефоны, өй телефоны)

Гариза

Мине, Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында, Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру (кадрлар резервына кертү) өчен, бәйгедә катнашуга кертүегезне сорыйм:

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________
(вазифа, структуралы бүлекчә)

2004 елның 27 июленән № 79-ФЗ “Россия Федерациясенә дәүләт гражданлык хезмәте күрсәтү турында”гы Федераль канун белән, 2005 елның 1 февраленнән № 112 “Россия Федерациясенә дәүләт гражданлык хезмәтенә буш урынны алмаштыру өчен бәйге турында”гы Россия Федерациясе Президенты Боерыгы белән,2003 елның 16 гыйнварыннан № 3-ЗРТ “Татарстан Республикасына дәүләт гражданлык хезмәте күрсәтү турында”гы Татарстан Республикасы Кануны, Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру (кадрлар резервына кертү) өчен бәйге уздыру турындагы Кагыйдәнамә, шул ук санда буш вазифага куела торган һөнәрчелек таләпләре белән таныштырылдым.

Бәйге уздыруның вакыты һәм урыны турында E-mail яки күрсәтелгән телефон номерына СМС –хәбәр аша хәбәр алу белән риза.

Гаризага беркетәм: (куелган документларны санап чыгарга).

______________________________________________________________________________

_______________ _________________ _____________________________
(вакыт) (имза) (имзаның шифрын чишү)

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен (кадрлар резервына кертү) бәйге үткәрү кагыйдәнамәсенә
3 нче кушымта.

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисенә
______________________________________
(инициаллар, фамилия)

**ГАРИЗА**

«  »________________20___ел.

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру (кадрлар резервына кертү) өчен, Сездән бәйге игълан итүегезне сорыйм.

______________________________________________________________
(вазифа исеме)

______________________________________________________________
(бүлек исеме)

Бу вазифаны алмаштыручы кандидатка киләсе таләпләр куела:

______________________________________________________________
(таләпләрне санап китәргә)

Кушымта: хезмәттәге регламентның күчермәсе.

_____________________  _______________  _____________________
(алмаштыра торган вазифа)  (имза)  (фамилия һәм инициаллар)

ЯРАШТЫРЫЛГАН
Комитет рәисе урынбасары

_______________  _______________
(имза, вакыт)  (фамилия һәм инициаллар)

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен (кадрлар резервына кертү) бәйге үткәрү кагыйдәнамәсенә 4 нче кушымта.

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисенә

________________________________
(фамилия һәм инициаллар)

Адрес:__________________________
________________________________

Хөрмәтле_________________________!

Сезгә, Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру (кадрлар резервына кертү) өчен бәйгегә кертелмәвегез турында хәбәр итәм.

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
__________________________________________________________________
(вазифа,бүлек исеме)

Сәбәбе:
(кирәклесен сайларга)

а) Татарстан Республикасына дәүләт гражданлык хезмәтендәге буш урынга куелган һөнәрчелек таләпләренә туры килмәү;

б) Татарстан Республикасына дәүләт гражданлык хезмәтенә керүгә һәм аны үтүгә, дәүләт гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы канунары белән урнаштырылган чикләүләр;

в) документларны үз вакытында тапшырмау ( аларны сәбәпсез тулы күләмдә бирмәү яки тутыру кагыйдәләрен бозу);

г) тикшерү барышында федераль кануннар, Татарстан Республикасы кануннары белән тәңгәл килеп, гражданинның Татарстан Республикасына дәүләт гражданлык хезмәтенә керергә комачау итә торган шартлар ачыклану;

Документлар сезгә язмача гариза белән түбәндәге адрес буенча кайтарыла ала. Казан, К.Тинчурин-29, 201 кабинет, Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты, телефон: 211 73 81.

Дәүләт хезмәте
һәм кадрлар секторы мөдире ___________________ _____________________
(имза) ( фамилия һәм инициаллар)

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен (кадрлар резервына кертү) бәйге үткәрү кагыйдәнамәсенә 5 нче кушымта.

БӘЙГЕ КОМИССИЯСЕНЕҢ БЕРКЕТМӘСЕ №________

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының бәйге комиссиясе утырышында, Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында дәүләт гражданлык хезмәтенең буш урынын алмаштыру өчен (кадрлар резервына кертү) бәйге сайлавы буенча тавыш бирү узды.

___________________________________________________________________________

(вазифаның исеме)

___________________________________________________________________________

(структур бүлекчәнең исеме)

Бәйге комиссиясенең ___ әгъзасыннан утырышта _____ булды.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:

1.____________________________________ «уңай»________, «каршы»_______.
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

2.____________________________________ «уңай»________, «каршы»_______.
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча:

___________________________________________________________________________

(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

бәйге комиссиясе әгъзаларының иң күп тавышын алды, ул сайлауда катнашкан комиссия әгъзалары саныннан_____ процент тәшкил итә.

| | | |
|---|---|---|
| Бәйге комиссиясе рәисе | ______________<br>(имза) | ________________________<br>(фамилия һәм инициаллар) |
| Бәйге комиссиясе рәисенең урынбасары | ______________<br>(имза) | ________________________<br>(фамилия һәм инициаллар) |
| Бәйге комиссиясе сәркатибе | ______________<br>(имза) | ________________________<br>(фамилия һәм инициаллар) |
| Бәйге комиссиясе әгъзалары | ______________<br>(имза) | ________________________<br>(фамилия һәм инициаллар) |

Бәйгене үткәрү вакыты «   »___________20___ел.